# Күкнең җиденче катында

## Кадерле укытучылар!

## Бу санда:

- Безнең теләкләр;
- Барысын да белергә телибез;
- Елмаеп алыйк…

Сезгә булган матур теләкләр
Шытып чыкты йөрәк түрендә.
Сәламәтлек, озын гомер, бәхет
Без телибез алгы көнегездә.

Хөрмәтебезне сезгә җиткерергә
Ниндиләрен алыйк бүләкнең?
Нинди генә бүләк аңлаталыр
Зур хисләрен безнең йөрәкнең?

Ихлас рәхмәтемне әйтер өчен
Ничек кенә табыйм сүзләрен.
Менә бүген чәчәк бәйләменең
Бирәм аңа иң-иң гүзәлен.




## Укытучы һөнәре

Укытучы – ул изге һөнәр. Балаларыбызның, халкыбызның киләчәге – укытучы кулында, аның алтын йөрәгендә. Шуңа күрә кеше тормышында укытучының роле һәм урыны бәяләп бетергесез. Укытучы исеменә лаек булу ул – зур бер батырлык дип әйтер идем мин. Ни өчен дигәндә: бары тик көчле рухлы, сабыр кеше генә бу эшкә күңелен биреп, тиешле дәрәҗәдә укыту сәләтенә ия була аладыр.

Талантлы укытучы үз тәҗрибәсен башкалар белән бүлешә, авырлыкларны җиңеләйтә, бала күңелен аңлый белә. Моның өчен укытучы булып туарга, гомереңбуе укытучы булып яшәргә кирәк. Укытучы ул һөнәр генә түгел, ул – аның язмышы! Алар балаларны белем дөньясына алып керәләр, яхшыны яманнан аерырга, хезмәт шатлыгын тоярга өйрәтәләр. Укытучы булу җиңел түгел! Укытучы һөнәре – чын мәгънәсендә һөнәрләр һөнәре. Мөгаллим ул – гомере буе укый, өйрәнә, үзенең һәм укучыларының уңышларына чын күңелдән сөенә белүче, көчле ихтыярлы, сабыр кеше. Балаларны яратучы, хөрмәт итүче, барачак юлларында маяк булып торучы изге зат. Бала күңеленә изгелек орлыклары чәчкәндә, бөтен тормыш тәҗрибәңне, белемеңне балаларга бирергә, күңел җылыңны өләшә белергә кирәк. Шул чакта чәчкән игелек, шәфкатьлелек орлыклары да тигез шытымнар бирә, үсә, тик алар корымасыннар гына иде! Аларны саклап калу – укытучыларның изге бурычы!

# БЕЗНЕҢ ТЕЛӘКЛӘР




«Хөрмәтле Диләрә Рүзәл кызы! Сезне бәйрәм белән котлыйм. Сезгә бәхет, саулык телим.»

Закиров Раул, 8 «Д» сыйныфы

«Хөрмәтле Александр Георгиевич! Сезне бәйрәм белән котлыйм. Сезгә озын гомер телим.

Сезнең фәнегез бик авыр, шул ук вакытта кызыклы да. Минем өчен, Сез - иң яхшы укытучы!»

Шәрәфетдинов Булат, 8 «Г» сыйныфы

«Хөрмәтле укытучыларыбыз! Сезне бәйрәм белән котлыйм! Сез һәрвакыт мөлаем булып калыгыз!»

Кадыйров Булат, 8 «Г» сыйныфы

«Кадерле Айсылу Фәрид кызы! Бәйрәмегез котлы булсын! Шатлык, куаныч, саулык телим Сезгә...»

Курняева Юлия, 8 «А» сыйныфы

«Кадерле Алсу Илдар кызы! Сезне күркәм бәйрәмегез белән котлыйм. Сезгә барысы өчен дә зур рәхмәт! Сезгә бу көнне бәхет, саулык, иң-иң изге теләкләремне юллыйм…»

Аипов Артур, 8 «Г» сыйныфы

«Хөрмәтле һәм яраткан укытучыларыбыз! Бәйрәмегез белән Сезне!»

8 «А» сыйныф укучылары

«Хөрмәтле, кадерле һәм яраткан укытучым Екатерина Сергеевна!

Без Сезне яратабыз, каникул вакытында сагынып киләбез. Бәхеттә яшәгез!»

Абрамова Анна, 7 «В» класс

«Хөрмәтле Алсу Шамил кызы! Һәрвакыт шундый ягымлы, тырыш, акыллы булып калыгыз!»

Чапкан Туана, 8 «Г» класс



# Барысын да белергә телибез...

**- ИДЕАЛ укытучы нинди булырга тиеш?**

- «Идеал укытучы – балаларны яратып, якын килеп эшләүче, юморны аңлый белә торган шәхес булырга тиеш.

Дәресне кызыклы һәм мавыктыргыч итеп алып баручы укытучы була.»

Абдуллина Алинә, 8 «Г» сыйныфы

**- «Укытучылар көне» ничек үтә ?**

- «Укытучы ул көнне бик яхшы кәеф белән уяна, мәктәпкә килә, яраткан укучылары аны бәйрәм белән котлыйлар, матур теләкләрен җиткерәләр.»

Яфясов Кәрим, 8 «Д» сыйныфы

- «Укытучы мәктәпкә килә, ишек төбеннән аны укучылары елмаеп, каршы алалар.»

Әхмәтгалиев Камил, 8 «Г» сыйныфы

**- Кайсы дәрес исегездә калды?**

- «Үзидарә көнендә миңа укучылар үткәргән география дәресе бик ошады. Без дәрестә төрле кызыклы сорауларга җавап бирдек, ребуслар, кроссвордлар чиштек.»

Закиров Раул, 8 «Д» сыйныфы

- «Миңа рус әдәбияты дәресе бик ошады. Төрле образларга кереп уку, күңелле иде... »

Хөснуллин Тимофей, 8 «А» сыйныфы

**- Сез укытучы һөнәрен үзләштерер идегезме?**

- «Мин укытучы булыр идем. Яраткан укучыларым белән аралашып, алар белән төрле бәйгеләрдә катнашып, рәхәтләнеп мәктәп тормышында кайнар идем.»

Еркузиева Мәрҗәнә, 7 «В» класс

**- Укытучы һөнәренең плюслары һәм минуслары.**

- «Минуслары: кәгазь эшләре бик күп.

Плюслары: балаларны киләчәктә батырлык эшләү өчен әзерли.»

Абдуллина Алинә, 8 «Г» сыйныфы

- «Бер яллары да юк. Шаккатам, алар барсына да ничек өлгерәләрдер...»

Куляев Азамат, 8 «Г» сыйныфы

- «Минем уенча, укытучы эшенең бер генә уңай ягы бар: билге кую.»

Закиров Раул, 8 «Д» сыйныфы

**- Укытучы нәрсә турында хыяллана?**

- «Тәрбияле укучылар, яхшы эш хакы турында.»

Никитин Данил, 8 «А» сыйныфы

- «Акыллы укучылар, ярдәмчел хезмәттәшләр.»

Әхмәтгалиева Камилла, 8 «Д» сыйныфы

- «Каллиграфик матур яза торган укучылар.»

Вәлиев Даниэль, 8 «Г»сыйныфы

- «Яхшы белем бирергә.»

Садыкова Аделина, 8 «Д» сыйныфы

# ЕЛМАЕП АЛЫЙК...

Әтисе һәм аның беренче сыйныфта укучы улы вокзалда поезд көтеп утыралар. Улы:

– Әти, безнең каршыда утыручы абый беләсеңме кем?

– Кем?

– Укытучы.

– Каян белдең?

– Утырыр алдыннан ул урындыкны бик җентекләп өйрәнде.

*******************************************************

Укытучы – Вәлигә:

– Синең бу билгеләреңне күргәч, атаңның чәчләре агарачак бит!

– Агармаячак!

– Нишләп?

– Чөнки аның башы пеләш!

********************************************************

Әнисе алты яшьлек улын хәреф танырга өйрәтә:

- Бу нинди хәреф?

- Ө-ө-ө.

- Ә бу рәсемдә нәрсә?

- Өтәч..

*********************************************************

Укучы иншасыннан:

«Моабит төрмәсендә Муса Җәлилнең башын кисәләр. Ләкин ул тез чүкми. Күп еллардан соң кабат Ватанга әйләнеп кайта...»

*********************************************************

Биология дәресе. Укытучы Айдардан сорый:

- Әйт әле, Айдар, яңгыр суалчаннары нинди юл белән үрчиләр?

- Бүленү юлы белән, апа!

- Ә ничек бүленәләр?

- Көрәк белән!

- Белмисеңме, безнең ташбака кая булды икән?

- Ишегалдында. Балаларга чикләвек ватыша.

*************************************************-

Сез скрипкада уйный беләсезме?

- Төгәл генә әйтә алмыйм... Бер дә уйнап караганым юк.

*************************************************

Автомәктәптә имтихан бара:

- Двигатель ничек эшли?

- Үз сүзләрем белән мөмкинме?

- Әлбәттә!

- Вжжжж! Вжжжж! Вжжжж!